ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2021 Казан ш. № 527-24/э-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-14/э карарына үзгәрешләр кертү һәм өстенлекле нигездә бер генә кулланучыга хезмәт күрсәтә торган «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2022 елга индивидуаль тарифларга һәм «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-14/э карары белән билгеләнгән индивидуаль тарифларга үзгәреш кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, «КАМАЗ» ГАҖ керә торган затлар төркемен тәгаенләштерү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының

кирәкле тулай табышына 2022 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Өстенлекле нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтә торган «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә индивидуаль тарифлар һәм «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020-2024 елларга индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 11 декабрендәге №3-14/э карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.01.2020 №4-1/э-2020 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-14/э карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 527-24/э-2021
карары редакциясендә)1 нче кушымта

## Өстенлек нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтүче «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә календарь буенча бүленгән бәяләр (тарифлар)

| т/с | Электр энергиясеннән (егәрлегеннән) файдаланучыларның тариф төркемнәре | Үлчәү берәмлеге | Ел | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте («КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте) өчен бер кулланучы тарафыннан түләнә торган тарифлар «КАМАЗ» ГАҖ затлар төркеменә түбәндәгеләр керә: «КАМАЗ» ГАҖ; «ПРОМЖЕЛДОРТРАНС-Сервис» ҖЧҖ; «ИНТЕРТРАНС-КАМАЗ» ҖЧҖ; «Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ; «КАМАЗ» сәүдә-финанс компаниясе» АҖ; «Автозапчасть «КАМАЗ» ҖЧҖ; «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» ҖЧҖ. | | | | | |
| 1.1 | Ике ставкалы тариф | | | | |
| 1.1.1 | - электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | сум/МВт*ай | 2020 | 27 101,32 | 27 101,32 |
| | | | 2021 | 27 914,36 | 27 914,36 |
| | | | 2022 | 52 909,67 | 52 909,67 |
| | | | 2023 | 29 614,34 | 29 614,34 |
| | | | 2024 | 30 502,77 | 30 502,77 |
| 1.1.2 | - электр челтәрләрендә технологик сарыфка (югалтуга) түләү ставкасы | сум/МВт*сәг | 2020 | 23,68 | 23,68 |
| | | | 2021 | 23,68 | 24,39 |
| | | | 2022 | 27,58 | 27,58 |
| | | | 2023 | 25,12 | 25,87 |
| | | | 2024 | 25,87 | 26,65 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.2 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт·сәг | 2020 | 0,07672 | 0,07672 |
| | | | 2021 | 0,07831 | 0,07902 |
| | | | 2022 | 0,13323 | 0,13323 |
| | | | 2023 | 0,08308 | 0,08384 |
| | | | 2024 | 0,08557 | 0,08635 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-14/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2021 № 527-24/э-2021 карары редакциясендә) 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь чорларына бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту өчен ставка | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 27 101,32 | 23,68 | 0,07672 | 27 101,32 | 23,68 | 0,07672 |
| | | 2021 | 27 914,36 | 23,68 | 0,07831 | 27 914,36 | 24,39 | 0,07902 |
| | | 2022 | 52 909,67 | 27,58 | 0,13323 | 52 909,67 | 27,58 | 0,13323 |
| | | 2023 | 29 614,34 | 25,12 | 0,08308 | 29 614,34 | 25,87 | 0,08384 |
| | | 2024 | 30 502,77 | 25,87 | 0,08557 | 30 502,77 | 26,65 | 0,08635 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-14/э карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 527-24/э-2021 карары
редакциясендә) 4 нче кушымта

«КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме
(югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтүче челтәр оешмасы исеме | Ел | Өстенлекле рәвештә бер генә кулланучыга хезмәт күрсәтүче челтәр оешмалары өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) раслаганда (хисаплаганда) исәпкә алынган челтәр оешмасының сарыфларын исәпкә алмаган кирәкле тулай кереме |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 | 93 032,54 |
| | | 2021 | 95 823,52 |
| | | 2022 | 153 697,94 |
| | | 2023 | 101 659,17 |
| | | 2024 | 104 708,94 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге